**Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Яңа Суыксу авылында гражданнар җыены карары**

15 ноябрь 2023 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Иске Суыксу авыл җирлегенең Яңа Суыксу авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Иске Суыксу авыл җирлегенең Яңа Суыксу авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Яңа Суыксу авылында юлларны төзекләндерүгә юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Иске Суыксу авыл җирлегенең Яңа Суыксу авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Иске Суыксу авыл җирлеге башлыгы _________ М.М. Дәүләтшин

Гражданнар җыены секретаре _________ Э.Ф. Билалова